Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының егерме сигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
карары

19 ноябрь, 2019 ел № 229

**Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнеше булган субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) торган авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 нче маддәсе нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнеше булган субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) торган авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен расларга. (Кушымта)

2. Әлеге карар нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәлгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Советының икътисади үсеш, бюджет, салымнар һәм финанслар мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашапов

Питрәч муниципаль районы
Советы карары белән расланды
19 ноябрь, 2019 ел № 229

## Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнеше булган субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) торган авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы (алга таба – Район) бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирүнең максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан район бюджетына бирелә торган субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) акчалары исәбеннән бирелә.

4. Әлеге кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче булып район башкарма комитеты тора.

5. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына район бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм район башкарма комитетына билгеләнгән тәртиптә әлеге кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

6. Башка бюджетара трансфертлар конкурсларда җиңүчеләр, грант алучылар һ.б. дип танылган Район авыл җирлекләре бюджетларына бирелә.

7. Башка бюджетара трансфертлар максатчан билгеләнеше нигезендә чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә җибәрелә.

8. Башка бюджетара трансфертлар түбәндәге критерийларга җавап бирә торган Район авыл җирлекләре бюджетларына бирелә:

а) Район авыл җирлеге территориясендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләре нигезендә сайлап алынган конкурслар призерлары, грантлар алучылар һ. б. булу;

б) Район башкарма комитеты тарафыннан раслана торган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында гариза булу.

9. Башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту шартлары булып тора:

а) әлеге кагыйдәләрнең 13 пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү төзү;

б) Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын районның авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәү.

10. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен, Район башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән вакытта, түбәндәге документларны Район башкарма комитетына тапшыра:

Район башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә гариза;

бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылуын раслаучы документлар.

11. Район авыл җирлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның күләме Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә исәпләнә.

12. Районның авыл җирлекләре бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү район башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый акты белән раслана.

13. Башка бюджетара трансфертлар Район башкарма комитеты һәм авыл җирлеге башкарма комитеты арасында Район башкарма комитеты тарафыннан расланган формалар нигезендә төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Килешүдә:

башка бюджетара трансфертларның күләме, аларның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансфертларны бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең әһәмияте;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертларны бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыру сроклары һәм формалары;

башка бюджетара трансфертларны алучының билгеләнгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

килешүдә каралган башка бюджетара трансфертларны алучының килешүдә каралган йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы карала.

15. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткече булып Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән критерийларга ирешү, әлеге максатларга акча бирү тора.

Район башкарма комитеты тарафыннан авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган хисапларга анализ ясау нигезендә нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүне бәяләү башкарыла.

16. Район авыл җирлекләре башкарма комитетлары килешүдә каралган форма һәм тәртип буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалану турындагы хисапны район башкарма комитетына тапшыралар.

17. Район башкарма комитетына тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләнә.

18. Башка бюджетара трансфертлар район башкарма комитеты тарафыннан авыл җирлекләре бюджетларына Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен

килешүдә билгеләнгән срокларда ачылган территориаль органнары счетларына күчерелә.

19. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Район бюджеты керемено күчерелергә тиеш.

20. Башка бюджетара трансфертларны бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә Район бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

21. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм, әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

22. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын Район башкарма комитеты һәм районның финанс-бюджет палатасы закон нигезендә контрольдә тота.